**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**«15» сентябрь, 2021 ел** **№ 103**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2018 елның 11 июлендәге 227 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2018 елның 11 июлендәге 227 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәгә (Советның 29.10.2018 № 258, 19.10.2020 № 9 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 12 пунктның 1) пунктчасында «автобиографияне» сүзен төшереп калдырырга;

2) 16 пунктта «гыйбарәт» сүзе алдыннан «тестлаштыру узудан һәм» сүзләрен өстәргә;

3) 17 пунктта «документларны» сүзе алдыннан «һәм тестлаштыру нәтиҗәләре буенча» сүзләре белән тулыландырырга;

4) 19 пунктта «нигезендә» сүзе алдыннан «тестлаштыру нәтиҗәләре, шулай ук» сүзләре белән тулыландырырга;

5) 20 пункт түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Тест узганнан соң кандидатлар турында фикер алышу һәм конкурс нигезендә сайлап алу конкурс комиссиясе утырышларында гамәлгә ашырыла».

2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, җирле үзидарә һәм җәмәгатьчелек белән элемтә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Г. Кәлимуллин